Республика Татарстан
Яурусовское сельское поселение
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районынын Янурыс авыл
жирлеге

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 1 феврале № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елнын 28 гыйнварындагы 73 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә, 6424,98 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.
2. «Җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 14 мартындагы 7 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 1 февраленнән «Янурыс авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2019 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU) урнаштырырга Татарстан Республикасы

«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А. Ә.Мөхәммәдиева

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 1 февралендәге 1 номерлы карарына
1 нче кушымта

2021 елның 01 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3700,80 |
| 3.Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1336,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1387,79 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 1 февралендәге 1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2021 елның 01 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1234,23 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2461,43 |
| 3.Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1336,39 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1392,93 |
| Барлыгы | 6424,98 |